**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

1 август 2018 ел № 84

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында**

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы **карар** итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. 2015 елның 10 ноябрендәге 16 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлегендә халык тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлекнең Уставында билгеләнгән тәртип буенча бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек Башлыгына йөкләргә.

**Башлык**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ” МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ**
**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ (ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ФИКЕР АЛЫШУЛАРНЫ)**
**ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә төзелде.

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘР

### 1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

**Халык тыңлаулары -** Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге (алга таба- муниципаль берәмлек) халкының җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кагылышлы муниципаль хокукый актлар проектлары буенча халык фикер алышулар аша җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында катнаша алу хокукларын тормышка ашыру формасы, шулай ук әлеге нигезләмәдә, федераль законнарда билгеләнгән сораулар буенча фикер алышулар да керә.

**Инициатив төркем-** халык тыңлауларында катнашу хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары төркеме яки гражданин;

**Җәмәгатьчелек вәкиле-** халык тыңлауларында катнашучы, теге яки бу сорау буенча фикер алышуда катнашу хокукына ия физик зат, шул исәптән юридик зат вәкиле. Җәмәгатьчелек вәкиленә халык тыңлауларында хезмәт вазифасы көче белән карар кабул итүче яки җирле үзидарә органы яки дәүләт власте вәкиле яки алар вазифасында түләүле килешү нигезендә катнашучы затлар керми.

**Халык тыңлаулары катнашучылары-** җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, халык тыңлаулары экспертлары, халык тыңлаулары үткәрү буенча оргкомитет әгъзалары;

**Чыгыш ясарга хокуклы халык тыңлаулары катнашучылары-**җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, әлеге нигезләмәнең 6 статьясына керүче, оргкомитетка сораулар буенча чыгыш ясау өчен заявкалар керткән җәмәгатьчелек вәкилләре;

**Оргкомитет**- халык тыңлауларын әзерләү, үткәрүне үз өстенә алучы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вазифаи затларыннан җыелган, авыл җирлеге Советы депутатларыннан төзелгән коллегалы орган;

**Җәмәгатьчелек фикер алышулар-** иҗтимагый мөһим сорауларны чишүдә халык фикерен җәмәгатьчелек контроленә алу максатыннан эшләнә. Шулай ук җирле үзидарә карары проекты һәм оешмалар, кирәкле карарга кагылучы гражданнар һәм җәмәгатьчелек берләшмәләре фикере.

**Халык тыңлаулары эксперты-** халык тыңлаулары сораулары буенча махсус белеме һәм аерым орган вәкиле статусына ия зат. Эксперт язмача киңәшләр бирә һәм халык тыңлаулары сорауларына тәкъдимнәр кертә, фикер алышуларда дәлилләр китерә.

2 статья. Халык тыңлауларын үткәрү максатлары

Халык тыңлаулары түбәндәге максатлардан чыгып үткәрелә:

муниципаль берәмлекнең әһәмиятле, мәҗбүри рәвештә халык катнашында халык тыңлауларына кертелә торган җирлек сораулары буенча муниципаль хокук актлары проектларын тикшерү;

халык тыңлауларына кертелгән сораулар буенча җәмәгатьчелек фикерен ачыклау һәм исәпкә алу;

Халык тыңлауларын әзерләү, үткәрү һәм нәтиҗәләрен ачыклау экспертларның ачыклыгы, хәбәрдарлыгы, ireклелеге, бәйсезлеге принциплары нигезендә гамәләгә ашырыла.

3 статья. Халык тыңлауларына кертелгән мәсьәләләр.

1. Халык тыңлаулары җирлекнең әһәмиятле мәсьәләләре буенча үткәрелә. Аларның нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен тәкъдим итү характерында карала.
2. Халык тыңлауларына мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр кертелә:

1) муниципаль берәмлекнең Устав проекты (алга таба- Устав). Шулай ук Уставка өстәлмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы Карары проекты Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль Законнар, (устав) конституцияләр яки Россия Федерациясе субъектлары Законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтелеп Уставка шул норматив актларга туры китереп үзгәрешләр керткән очрактан башка.

2) җирле бюджет һәм аның үтәлеше турында отчет проекты;

3) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади стратегияләр үсеше проекты;

4) муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә халык ризалыгы алу халык

җыеннарында тавыш бирү юлы белән тормышка ашырылу таләп ителү очрагыннан башка;

5) генераль план проекты, җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләр проекты, тирә- якны планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, шушы расланган документларның берсенә үзгәртүләр кертүне күздә тоткан проект, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектын яки җир кишәрлеген куллану өчен рөхсәт бирү турында карар проекты, рөхсәт ителгән төзелештән читкә тайпылырга мөмкинлек биргән карар проекты, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, куллануга рөхсәт ителгән җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектларын җирдән файдалану һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, башка төргә үзгәртү мәсьәләләре.

6) ачык сервитутлар билгеләү мәсьәләләре;

7) җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты;

8) федераль законнарда билгеләнгән башка мәсьәләләр.

3. Һәр мәсьәлә буенча бөтен яклап тулы фикер алышуга комачауламый икән, берничә мәсьәлә буенча бер үк вакытта ачык тыңлаулар үткәрү рөхсәт ителә.

4. Халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү башка чарасы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнмәгән булса, җирле бюджет акчалары хисабына финанслана

## 4 статья. Халык тыңлаулары инициаторлары

Халык тыңлаулары халык инициативасы буенча, җирлек Советы (алга таба- Совет), җирлек башлыгы (алга таба- Башлык) инициативасы буенча Регламент нигезендә үткәрелә.

Халык тыңлаулары үткәрү бунча халык инициативасы 18 яшькә җиткән 30 кешедән дә ким булмаган гражданнар төркеменнән чыгарга мөмкин.

# 2 бүлек. ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫНЫҢ БИЛГЕЛӘНЕШЕ

## 5 статья. Халык тыңлауларының билгеләнеше

1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган халык тыңлаулары Совет карары белән билгеләнә.

Башлык инициативасы белән үткәрелә торган халык тыңлаулары башлык тарафыннан билгеләнә.

Халык тыңлаулары Россия Федерациясе законнары белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.

2. Халык тыңлауларын үткәрү турында халык инициативасын күрсәтү өчен һәм халык имзаларын җыю өчен 10 кешедән ким булмаган инициатив төркем формалаштырыла.

2.1. Инициативалы төркем Советка түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

- гражданнарның инициатив төркеме вәкиле тарафыннан 1 нче кушымтадагы форма нигезендә имза салынган, халык тыңлаулары мәсьәләсен күрсәтеп, ачык тыңлаулар билгеләү һәм аларны үткәрү кирәклеген нигезләү турында гариза;

- муниципаль хокукый акт проекты (халык тыңлауларында карауга кертелгән очракта);

- муниципаль хокукый акт кабул итү зарурлыгын үз эченә алган, аның максатлары һәм төп нигезләмәләре күрсәтелгән аңлатма язуы (халык тыңлауларында карауга кертелгән очракта);

- финанс- икътисади нигезләү (бу очракта халык тыңлауларында муниципаль хокукый актны карау өчен кертелә, өстәмә һәм матди чыгымнар таләп ителә);

- 2 кушымтадагы форма нигезендә гражданнарның инициатив төркем исемлеге;

- гражданнардан инициатив төркем төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәләре;

- инициатив төркем вәкаләтле вәкиле имзалаган, инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән документларның кәгазь санын күрсәтеп, бергә теркәп җибәрелә торган хат. Шулай ук муниципаль хокукый акт проекты доклады (халык тыңлауларында карауга кертелгән очракта).

Гариза һәм беркетмәләр инициатив төркем рәисе (гражданнарның инициатив төркеме вәкиле) һәм сәркатибе тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

2.2. Әлеге матдәнең 2.1 бүлегендә билгеләнгән барлык документлар бер үк вакытта Советка тәкъдим ителсә, гариза бирелгән санала.

2.3. Советка гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар кергән соң, 30 көн эчендә инициатив төркем тарафыннан тыңлаулар үткәрү инициативасын хуплаучы халыкның имзалары әлеге Нигезләмәнең 3 кушымтасындагы форма нигезендә бирелергә тиеш. Муниципаль берәмлек халкының 18 яшьтән алып, кимендә 20 имзасы булырга тиеш.

Имзалар Советка тыңлаулар үткәрү тәкъдим ителгән инициатива турында гариза биргән көннән соң җыела ала. Кульязма рәвешендә язылмаган яки карандаш белән язылган мәгълүматлар кертергә рөхсәт ителми. Гражданнар турында тиешле мәгълүматлар һәм аларны кертү даталарында кул кую кәгазендәге төзәтүләр гражданнар һәм имзалар җыючылар тарафыннан билгеләнергә тиеш.

2.4. Совет эш төркеме оештыра һәм кул кую кәгазендә бирелгән мәгълүматларны, кул кую кәгазен тәкъдим иткән көннән соң, 10 көн эчендә тикшерә.

Кул кую кәгазьләрендә булган имзаларны һәм мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча имза гамәлдә яисә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

Әлеге Нигезләмә нигезендә имзаның гамәлдә булмавы билгеләнмәгән очракта, имза гамәлдә булып санала.

Кул кую яки язылышу кәгазен җыю тәртибен бозып җыелган имзалар гамәлдә түгел дип таныла:

1) имза җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2) 18 яше тулмаган муниципаль берәмлек халкының имзалары;

3) гражданнарның имзаларын кул кую кәгазенә үз кулың белән кертү датасын күрсәтмәгән имзалар;

4) кул кую кәгазенә кулъязма рәвешендә язылмаган яки карандаш белән кертелгән имзалар;

5) гражданнар һәм имзалар җыючылар тарафыннан махсус билгеләнмәгән очракта грандҗаннар турында мәгълүматка һәм кул кую даталарына төзәтүләре керткән очракта;

6) кул кую кәгазендә барлык имзалар да, аның формасы әлеге Нигезләмәнең 3 кушымтасы таләпләренә туры килми.

Тикшерү нәтиҗәләре кул кую битләрен тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (4 кушымта).

2.5. Советның чираттагы утырышында, 15 көнлек срокта кул кую кәгазе кергән көннән соң, халык тыңлаулары билгеләү турында Карар кабул ителә яки түбәндәге очракларда халык тыңлауларын билгеләү турында гариза кире кагыла:

1) ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәләләр, әлеге Нигезләмәнең 3 нче матдәсендә каралган очраклардан тыш, җирле үзидарә органнары компетенциясенә керми;

2) халык алдында тыңлаулар үткәрү турында халык инициативасын күрсәтү өчен тәкъдим ителгән гамәлдәге имзалар саны җитәрлек түгел;

3) инициатива күрсәтү тәртибе үтәлми;

4) тикшерүгә тәкъдим ителгән муниципаль норматив хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар нигезләмәләренә һәм башка норматив хокукый актларга туры килми,

5) халык тыңлауларын үткәрү датасыннан башлап, аларга шундый ук сорау чыгарылган, бер елдан да ким вакыт үткән.

2.6. Халык тыңлауларын билгеләү турында гаризаны кире кагу, бозуларны бетергән очракта ачык тыңлаулар билгеләү өчен, инициативалы төркем тарафыннан документлар кабат кертү өчен киртә булып тормый.

2.7. Халык тыңлауларын билгеләү турындагы мәсьәлә Совет Регламенты нигезендә карала.

2.8. Халык тыңлауларын билгеләү турында гариза кире кагылган очракта, Совет эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта гражданнарның инициатив төркеме вәкиле адресына язма мотивлаштырылган белдерү җибәрә.

3. Халык тыңлауларны билгеләүче Совет, Башлык, тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны, оештыру комитеты составы, тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе һәм халык алдында тыңлаулар вакытында чыгарыла торган муниципаль хокукый акт проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган тиешле муниципаль актлар кабул итә

Федераль законнар, Устав һәм әлеге Нигезләмә белән башкача билгеләнмәгән очракта тыңлаулар үткәрү датасы ачык тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт кабул ителгән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

6 статья. Җәмәгать тыңлаулары турында мәгълүмат бирү.

1. Муниципаль берәмлек халкына халык тыңлауларын билгеләү турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында, рәсми сайтта һәм (яки) башка мәгълүмат системаларында, мәгълүмати стендта халык тыңлаулары үткәрү көненә

кадәр (әгәр башкасы Федераль закон, Устав, әлеге Нигезләмә белән каралмаган булса) календарь көннәрендә 10 көнлек вакыт өчендә халык тыңлауларын билгеләү турында муниципаль хокукый актны (әгәр дә ул халык тыңлауларына кертелгән очракта) бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.1. Халык тыңлауларының нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы официаль сайтының җирлек бүлегендә, башка мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат стендларында басылып чыга.

Кулланучылар өчен мәгълүмат алу мөмкинлеген исәпкә алып, мәгълүмати стендлар яхшы күренә торган урыннарда җиһазлана.

Мәгълүмат стендларын урнаштыру мәгълүмат кулланучынысын озак вакыт мәҗбүри җайсыз позада тору зарурлыгына юл куймый торган эргономика таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш.

2. Мәгълүмат стендларын урнаштыру озак вакытлар мәҗбүри булмаган вакытта мәгълүмат кулланучыны табу зарурлыгына юл куймый торган эргономика таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны төсләре бизәү эстетик таләпләргә туры килергә тиеш. Мәгълүмати стендлар А4 форматындагы кесәләргә мәгълүмати битләр урнаштырылып, җиһазландырылырга мөмкин.

3. Халык тыңлауларында яки җәмәгать фикер алышуларында карала торган проект экспозициясе урнаштыру урыны, шулай ук үткәрү мәйданы каралырга тиеш, шулай ук проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү вакыты, ачык тыңлаулар яки җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелә.

Экспозиция эшләгән чорда килүчеләр өчен консультацияләрдә, проект турында басма мәгълүмат материалларын тарату оештырыла. Экспозициягә килүчеләр фикер алышына торган проектка карата үз тәкъдимнәрен, искәрмәләрен, экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу һәм тәкъдимнәр, искәрмәләр язу өчен тиешле китапка (журналга) язмача рәвештә кертергә хокуклы.

Проект экспозициясенә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

- проект;
- проектка аңлатма язуы;
- Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә алынган документлар килешүләренең күчермәләре;
- проект буенча халык тыңлаулары яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында күрсәтеп, бастырып чыгарган күчермә;

- фикер алышына торган проект буенча гражданнарга мәгълүмат бирү максатларында , мондый материаллар проектны оештыручы тарафыннан тәкъдим ителгән очракта, мәгълүмати һәм демонстрацион материаллар.

## 3 бүлек. ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ ҮТКӘРҮ

### 7 статья. Халык тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү

1. Халык тыңлаулары муниципаль берәмлек халкы өчен уңайлы вакытта үткәрелә (тыңлауларны эш көне булмаган көннәрдә 11.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр яки эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 22.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча үткәрергә киңәш ителә)

2. Халык тыңлауларын билгеләү турында Карар кабул иткән җирле үзидарә органы оештыру комитетын (әгәр ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы булып гражданнарның инициатив төркеме чыгыш ясаса) Совет депутатлары, муниципаль берәмлек башкарма комитеты хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар, гражданнарның инициативалы төркеме вәкилләре арасыннан, кимендә 5 кешедән формалаштыра.

Оештыру комитеты оешканнан соң, 3 көннән дә соңга калмыйча, беренче утырышта үз составыннан рәисне, рәис урынбасарын һәм секретарен сайлый.

Утырышта оештыру комитетының яртысыннан артык әгъзасы катнашса, ул карар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру комитеты тыңлауларда катнашырга теләүче тыңлаулар үткәрелә торган бинага тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Оештыру комитеты тыңлауларда катнашырга теләүче тыңлаулар үткәрелә торган бинага тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Халык тыңлауларын үткәрү көнендә оештыру комитеты ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Ачык тыңлауларда рәислек итүче булып оештыру комитеты рәисе тора.

Рәислек итүче ачык тыңлауларны ача, халык тыңлаулары соравын (сорауларын), тыңлауларны үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәр игълан итә, үзен, секретарен һәм экспертларын тәкъдим итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә. Оештыру комитеты секретаре ачык тыңлаулар беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче фикер алышу үткәрелә торган сорау турында игълан итә һәм ачык тыңлаулар үткәрү инициаторлары тарафыннан вәкаләтле затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясарга хокукы булган ачык тыңлауларда катнашучыларга сүз бирә. Чыгышлар оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән гаризалар бирү чираты белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар да, үз тәкъдимнәрен кире алырга яки башка катнашучыларның тәкъдимнәренә кушылырга хокуклы.
Фикер алышу йомгакларыннан , халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан чыгарылган тәкъдимнәрдән, җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча бердәм исемлек төзелә.

6. Рәислек итүче белән йомгаклау документын төзегәннән соң тәкъдимнәр һәм тәкъдимнәр белән катнашучыларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итүнең йомгаклау вариантын тавышка куя. Ачык тыңлауларда

карарлар ачык тавыш бирү юлы белән тыңлауларда теркәлгән катнашучылар саныннан күпчелек гади тавыш бирү белән кабул ителә. Тыңлауларда катнашкан һәр кеше җирле әһәмияттәге мәсьәләне тәкъдим иткән карар өчен бер тавыш бирә, каршы яисә тавыш бирүдән тыелып кала. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә. Беркетмәгә рәислек итүче һәм ачык тыңлаулар секретаре имза сала.

7. Ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә, ачык тыңлаулар уздырылган көннән соң, 3 эш көнендә  халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында (№6 кушымта) бәяләмә төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) халык тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә (сораулар);

2) халык тыңлаулары үткәрү инициаторы;

3) ачык  тыңлауларны  билгеләү турында хокукый актның датасы, номеры һәм исеме, шулай ук аны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) датасы;

4) халык тыңлаулары үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

5) ачык тыңлауларны уздыручы оештыру комитеты;

6) ачык тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясау хокукына ия булучылар турында мәгълүмат;

7) халык тыңлауларында катнашучылар әйткән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге;

8) җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;

9) халык тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

8. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә оештыру комитеты рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана һәм ачык тыңлаулар уздырылган көннән алып 3 көнлек эш вакытында  исәпләнгән срокта басылып чыгарга (халыкка хәбәр ителергә) тиеш.

9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә тыңлауларда чыгарылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен җаваплы җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Тикшерү нәтиҗәләре мәҗбүри рәвештә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне караганнан соң, 3 көнлек срокта бастырып чыгару (халыкка игълан итү) юлы белән муниципаль берәмлек халкына җиткерелә.

10. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш тәкъдим итү характерына ия.

## 4. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК УСТАВЫ  ПРОЕКТЫ, УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ ТУРЫНДА ХИСАП, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕ ҮЗГӘРТЕП КОРУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА, АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

8 статья. Муниципаль берәмлек Уставы проектын һәм уставка үзгәрешләр кертү турында Совет карары проектын ачык тыңлауларда карау үзенчәлекләре

1. Устав проекты, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Уставта каралган үзенчәлекләрне исәпкә алынып ачык тыңлауларда карала.

2. Устав проекты,Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты Совет тарафыннан аны кабул итү турындагы мәсьәлә каралганчы 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аның фикер алышуында катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында Совет карары басыла.

Уставка өстәлмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы Карары проекты Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль Законнар, (устав) конституцияләр яки Россия Федерациясе субъектлары Законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтелеп Уставка шул норматив актларга туры китереп үзгәрешләр керткән очракта проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен рәсми рәвештә бастырып чыгару таләп ителми.

3. Ачык тыңлаулар Устав проекты яки Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча устав белән билгеләнгән вакытта, әмма әлеге проектлар басылып чыкканнан соң, 10 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта уздырыла.

4. Устав проекты яки муниципаль хокукый акт Советының муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып, оештыру комитеты тора.

9 статья. Ачык тыңлауларда җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны карау үзенчәлекләре

1. Ачык тыңлауларда җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында еллык хисап Россия Федерациясе Бюджет кодексында, башка федераль законнарда, Уставта каралган үзенчәлекләрне, муниципаль берәмлектә бюджет процессы турындагы нигезләмәләрне исәпкә алып карала.

2. Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча ачык тыңлаулар үткәрүне гамәлгә ашыручы орган булып, оештыру комитеты тора.

Ачык тыңлауларны билгеләү турында Карар кабул итүче орган булып, җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тора.

3. Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карарлар, җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап аларны кабул иткәннән соң, 10 көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлаулар, җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап, җирле бюджет проекты басылып чыкканнан соң, 15 календарь

көннән дә иртәрәк үткәрелми

## 10 статья. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын карау үзенчәлекләре

Ачык тыңлауларга муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектларына кагылышлы сораулар проекты "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, "Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып кертелә.

## 11 статья. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләсен карау үзенчәлекләре.

1. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләсе "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм әлеге Законның 13 статьясындагы 5 өлешеннән калган очракларда уздырыла.

3. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләсен оештыру комитеты тора.

## 12 статья.Ачык тыңлауларда яисә җәмәгать фикер алышуларында муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча мәсьәләләрне карау үзенчәлекләре.

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияне межалау проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тота торган проектларга, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектларына кагылышлы мәсьәләләр, шулай ук Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, җәмәгать фикер алышуларына чыгарылырга мөмкин.

Ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре шәһәр округларының генераль планнары проектлары буенча, җирлекләрнең генераль планнары проектлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясында күрсәтелгән.

Генераль планнар проектлары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар җирлектәге муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә (алга таба-җәмәгать фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар).

Җәмәгать фикер алышулары яисә ачык тыңлауларны уздырганда, әлеге чараларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында, торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Җәмәгать фикер алышулары яисә ачык тыңлауларны үткәрү вакыты муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән вакыттан алып җәмәгать фикер алышулар яисә ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырган көнгә кадәр берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм ул бер айдан да ким булмаска тиеш.

Җәмәгать фикер алышуын яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, җирле администрация башлыгы карар кабул итә:

1) генераль план проекты белән килешү турында һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына җибәрү турында;

2) генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында.

13 статья. Ачык тыңлауларны ачык сервитут билгеләү буенча үткәрү үзенчәлекләре.

1. Ачык сервитут билгеләү буенча, ачык тыңлауларда катнашу хокукына, ачык сервитут билгеләнә торган муниципаль берәмлектә даими рәвештә яки кубесенчә яшәүче тыңлаулар үткәрелә торган көнгә 18 яше тулган һәр граждан ия.

Гражданнарның җәмәгать тыңлауларында катнашуы ирекле нигездә гамәлгә ашырыла.

Җәмәгать тыңлауларында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан барлык милек формаларының коммерциячел булмаган һәм коммерция оешмалары катнаша ала.

2. Ачык тыңлаулар 13 статьяның 1 нче пунктында күрсәтелгән вәкаләтле орган яисә физик һәм юридик затлар инициативасы буенча үткәрелә.
Халык тыңлауларын үткәрү буенча вәкаләтле органы булып оештыру комитеты тора.

3. Вәкаләтле орган ачык тыңлаулар үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң, 7 эш көне эчендә аларны муниципаль берәмлекнең муниципаль актларын бастырып чыгару өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында белдерү бастыра.

Җәмәгать тыңлаулары ачылыр алдыннан, катнашучылар турында түбәндәгеләрне күрсәтеп, мәҗбүри теркәү үткәрелә:

юридик зат- юридик затның тулы исеме, белешмәләре;

шәхси эшмәкәр сыйфатында гражданны дәүләт теркәвенә алуның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм белешмәләре;

физик затлар- фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елның адресы, яшәү урыны.

4. Ачык тыңлауларның нәтиҗәсе беркетмә белән рәсмиләштерелә, анда аларны үткәрү датасы һәм урыны, катнашучылар һәм катнашучыларның саны, рәиснең исеме, атасының исеме, ачык тыңлаулар секретаренең исеме,

чыгышларның эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм халык тыңлаулары рәисе һәм Секретаре тарафыннан имзалана. Беркетмәгә халык тыңлауларында катнашучылар исемлеге куела.

5. Ачык сервитут билгеләү турында ачык тыңлаулар нәтиҗәләре вәкаләтле орган тарафыннан карала һәм аның тарафыннан очык сервитут билгеләү өчен кирәк булган документларга кертелә.

Ачык сервитутны билгеләү буенча ачык тыңлаулар беркетмәләрен саклау срогы- өч ел. Ачык сервитутны билгеләү буенча, ачык тыңлаулар беркетмәләрен саклау өчен җаваплы вәкаләтле орган җитәкчесе тора.

14 статья. Ачык тыңлауларда җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын карау үзенчәлекләре

1. Җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты буенча, ачык тыңлаулар “Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә.

---

1 кушымта

ЗАЯВЛЕНИЕ
О НАЗНАЧЕНИИ ПУБЛИЧНЫХ СЛУШАНИЙ

Инициативная группа в количестве ______ человек, список прилагается, предлагает назначить по инициативе населения муниципального образования ______________________________________________ публичные слушания по вопросу:
__________________________________________________________________________

Обоснование необходимости проведения публичных слушаний:
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Приложение (указываются фактически представляемые документы):

1) проект муниципального правового акта (в случае внесения);

2) пояснительная записка;

3) финансово-экономическое обоснование (в случае внесения муниципального правового акта, реализация которого потребует дополнительных материальных и иных затрат);

4) список инициативной группы граждан;

5) протокол собрания, на котором было принято решение о создании инициативной группы граждан;

6) сопроводительное письмо.

Уполномоченный представитель
инициативной группы граждан ______________ ______________
(подпись) (Ф.И.О.)

Секретарь
инициативной группы граждан ____________ ______________
(подпись) (Ф.И.О.)

2 кушымта

СПИСОК
ЧЛЕНОВ ИНИЦИАТИВНОЙ ГРУППЫ

| № п/п | Фамилия, имя, отчество и год рождения (в возрасте 18 лет - число и месяц рождения) | Адрес места жительства | Паспортные данные серия, номер документа, удостоверяющего личность, кем и когда выдан) | Личная подпись |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Уполномоченный представитель
инициативной группы граждан ________________ ________________
(подпись) (Ф.И.О.)

3 кушымта

ПОДПИСНОЙ ЛИСТ
ПУБЛИЧНЫХ СЛУШАНИЙ

По вопросу:
«______________________________________________________________________________
_________________________________________________________________»

Мы, нижеподписавшиеся, поддерживаем проведение публичных слушаний по инициативе населения муниципального образования _______________________ по вопросу: «______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________
______________________________________________________________»

| № п/п | Фамилия, имя, отчество | Год рождения в возрасте 18 лет (дополнительно число и месяц рождения) | Адрес места жительства | Серия и номер паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина | Личная подпись |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Подписной лист удостоверяю:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(фамилия, имя, отчество, серия, номер и дата выдачи паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, с указанием наименования или кода выдавшего его органа, адрес места жительства лица, собиравшего подписи, его подпись и дата ее внесения).

Уполномоченный представитель
инициативной группы граждан ______________ ______________
(подпись) (Ф.И.О.)

4 кушымта

# ПРОТОКОЛ
# ПРОВЕРКИ ПОДПИСНЫХ ЛИСТОВ ПУБЛИЧНЫХ СЛУШАНИЙ

По вопросу:
«_______________________________________________________________________________
________________________________________________________________».

Количество представленных в Совет муниципального образования __________________ подписей граждан, поддерживающих инициативу проведения публичных слушаний ____________________________________________________________.

Проверено подписей избирателей ___________, из них признаны:
недействительными ________________ по следующим причинам:
___________________________________________________________________;
___________________________________________________________________.

Количество недействительных подписей - ______________________________.

Из фактически представленных в Совет, общее количество действительных подписей составляет ______________.

Руководитель Рабочей группы ________________ ___________
(подпись) (Ф.И.О.)

Члены Рабочей группы ______________________ __________________
(подпись) (Ф.И.О.)

_______________ _____________
(подпись) (Ф.И.О.)

__________________________
(дата, время)

Уполномоченный представитель
инициативной группы граждан ______________ ______________
(подпись) (Ф.И.О.)

Секретарь
инициативной группы граждан ____________ ______________
(подпись) (Ф.И.О.)

5 кушымта

# ПРОТОКОЛ
# ПУБЛИЧНЫХ СЛУШАНИЙ

«____» _________ 20__ г.                                        № _____

г.___________

Публичные слушания по инициативе:
_________________________________________________________________ назначены
_________________________________________________ от ____________ № _____
(муниципальный правовой акт)
___________________________________________________________________________
(наименование муниципального правового акта)
опубликованным
(обнародованным):__________________________________________________проведены
__________________________________________________________________ по адресу:
____________________________________.__________________________________
(дата проведения)

Оргкомитет:_________________________________________________________________

Присутствовали: _____________________________________________________

Председательствующий: _______________________________________________

Секретарь: _________________________________________________________

Эксперты: _________________________________________________________

Участники публичных слушаний: (количество зарегистрированных участников)
______________________________________________________________________

Участники, выступающие на публичных слушаниях:
___________________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

Слушали:
1.______________________________________________________________________
(Ф.И.О.)
2. ______________________________________________________________________
(Ф.И.О.)
3. ______________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

Количество внесенных рекомендаций и предложений в устной и письменной форме ______________________, в том числе:

| № п/п | Рекомендации и предложения | Заявитель |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Председательствующий публичных слушаний______________ _________________________
(подпись) (Ф.И.О)

Секретарь публичных слушаний________________________ _________________________
(подпись) (Ф.И.О)

6 кушымта

ЗАКЛЮЧЕНИЕ
О РЕЗУЛЬТАТАХ ПУБЛИЧНЫХ СЛУШАНИЙ

«___» _________ 20__ г. г. ___________

Публичные слушания по инициативе: ______________________________________ назначены ____________________________________________________________________
(муниципальный правовой акт)
от _____№ _____ ______________________________________________________________
(наименование муниципального правового акта)
опубликованным (обнародованным):___________________________________ проведены по адресу:____________________________________ ________________________________
(дата проведения)

Вопрос (вопросы), выносимые на публичные слушания_________________________________
Инициатор проведения публичных слушаний
________________________________________
Дата, время и место проведения публичных слушаний
________________________________
Оргкомитет, проводивший публичные слушания______________________________________

Информация об участниках публичных слушаний, в том числе получивших право на выступление __________________________________________________________

Единый список предложений и рекомендаций по решению вопроса (вопросов) местного значения, вынесенного на публичные слушания:

| Вопросы, вынесенные на обсуждение | | Предложения и рекомендации экспертов и участников | | Предложения рекомендации) внес поддержаны) | Примечание |
|---|---|---|---|---|---|
| № п/п | формулировка вопроса или наименование проекта | № п/п | текст предложения | Ф.И.О. эксперта участника) | |
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

Итоговый вариант решения вопроса местного значения: _______________________________

Результаты голосования участников публичных слушаний:

за _______________________ (чел.)
против___________________ (чел.)
воздержались____________ (чел.)

Председатель оргкомитета ________________________________

Секретарь оргкомитета _________________________________